СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
№1-39

КАРАР
«21» март 2019 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 03.03.2016 ел, 1-7санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 20 декабрендәге 106 –ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы , "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы" нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 03.03.2016 ел, 1-7 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 ел, № 2-15, 10.05.2017 ел, № 1-20, 28.07.2018 ел, № 2-21, 14.11.2017 ел, № 1-25, 05.06.2018 ел, №2-31, 13.08.2018 ел, № 2-13, 20.11.2018 ел, № 3-36, 14.12.2018ел №4-37 редакциядәге үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.8. 7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 7.4. пунктчасы белән тулыландырырга:

"7.4. Җитәкче булып эшләүче муниципаль хезмәткәр, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында муниципаль берәмлекнең әлеге җирле үзидарә органының һөнәр берлеге органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатен кайгырта алмый."

1.9. 8.1. пунктында:

" сәяси партия белән;" сүзләреннән соң "түләүсез нигездә һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан " сүзләре белән тулыландырырга.;

"бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылыр кооперативы," сүзләрен төшереп калдырырга;

"сәяси партиядән башка" сүзләреннән соң һәм һөнәр берлеге органыннан шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл жирлеге башлыгы С.Н.Степановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Степанов С.Н.